Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 11 (24)

12 апрель 2012 ел

## • Ректорат яңалыклары

9 апрель көнне ректоратның чираттагы утырышы үтте.

Беренче булып, фәнни эшчәнлек буенча проректор Данис Нургалиев Канадада узган бер атналык визит нәтиҗәләре белән таныштырды. Шулай ук утырыш вакытында «Шлюмберже» компаниясе белән КФУ арасындагы хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куелды.

Алга таба ТР «Алгарыш» грантына кандидатлар исемлеге белән танышу булды. Программада Казан федераль университетыннан барлыгы 35 кеше катнаша. Шуны ассызыкларга кирәк, быел стажировкага баручыларны уку йорты финанслый. Ректор һәм утырышта катнашучылар Страсбург (Франция), Сарагосы (Испания), Көнчыгыш Англия (Бөекбритания) кебек дөньяның төрле университетларына китәчәк студент, аспирант һәм фәнни хезмәткәрләргә төрле сораулар бирде. «Сез – университетның элитасы. Барлык белем-тәҗрибәләрне яхшылап өйрәнегез, туган ягыгызга кайткач, яшьтәшләрегез белән уртаклашырлык булсын. Уку йорты, республика сезгә зур өметләр баглый», – диде ректор.

КФУ ның Үсеш программасы турында икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор Марат Сафиуллин мәгълүмат җиткерде.

Һәр ректорат саен институт җитәкчеләре үз бүлекләренең үсеш программасы белән таныштыра. Бу юлы Тарих институты турында директор Рамил Хәйретдинов презентация тәкъдим итте. Институт КДУ ның тарих факультеты һәм ТДГПУ ның тарихи белем бирү факультеты базасында 2011 елның 26 мартында оеша. Җитәкче институттагы яңа укыту программалары, ачылачак кафедралар, уздырылачак халыкара конференцияләр, тикшеренү проектлары турында сөйләде. Шулай ук Тарих институты «Мирас», «Яңарыш» дәүләт проектларын тормышка ашыруда ярдәм итә. Рамил Равил улы КФУ ның Кече университеты эшчәнлегенә дә тукталды. Әлеге проектта 900 дән артык бала катнаша, Алабуга институтында филиалы ачылды. Киләчәктә Халыкара балалар лагере оештыру, Балалар университетының Европа ассоциациясе составына керү планлаштырыла. Рамил Хәйретдинов чыгышыннан соң ректор үз тәкъдимнәрен җиткерде. «ТР ның Фәннәр академиясендә, Россия Фәннәр академиясенең Казан милли үзәгендә эшләүче КФУ укытучылары үз басмаларында безнең уку йортында эшләүләрен күрсәтмиләр. Әлеге гамәлне туктатырга вакыт җитте. Университетның мәнфәгатьләрен ныграк кайгыртырга кирәк», – диде.

Алга таба кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе Сергей Ионенко 2012 елда кабул итүгә әзерлек турында мәгълүмат бирде, БДИ һәм дәүләт имтиханына (ГИА) әзерлек буенча III Республикакүләм Интернет-форум, ТР мәктәпләрендә 9 һәм 11 сыйныфлар өчен уздырылган Интернет-тест нәтиҗәләре белән таныштырды. Югары сыйныф укучылары нәкъ менә КФУга өстенлек бирә икән.

Административ эшләр буенча проректор – аппарат җитәкчесе Андрей Хашов «Алабуга» үзенчәлекле икътисади зонасында ТР ның министрлык, идарә вәкилләре һәм КФУ хезмәткәрләре катнашында узачак киңәшмә турында мәгълүмат җиткерде.

Уку-укыту эшләре буенча проректор Рияз Минзарипов университет составында ачылачак 7-11 сыйныф укучылары өчен IT-лицей-интернат турында сөйләде. Алдагы уку елыннан Универсиада авылында урнашып эшли башлаячак лицейда 10-11 сыйныф укучыларына иң яхшы мәктәп укытучылары һәм КФУ педагоглары белем бирәчәк.

Ректорат ахырында җәмәгатьчелек белән элемтәләр бүлеге җитәкчесе Ләйлә Мөхтәрова портал эшчәнлеге турында сөйләде. Аның сүзләренчә, иске сайттагы мәгълүматларның күбесе яңа порталга күчерелде, ләкин шулай да кайбер бүлек сайтларын тутырып бетерәсе бар. Ректор Илшат Гафуров порталның төп битендә ТР ның, РФ ның Мәгариф һәм фән министрлыклары сайтына чыгарырдай сылтамаларны куярга, тиз арада сайтның инглиз телендәге вариантын әзерләргә кушты.

*Динара ӘХМӘТОВА,*
*хәбәрче*



Алия Галимуллина фотосы

# Таләпләргә туры китереп

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Резидентларның зур тизлек белән үсүе «Алабуга» үзенчәлекле икътисади зонасында кадрларга бәйле җитди проблемалар китереп чыгарды. Әлеге сорауларны чишү уңаеннан, 10 апрель көнне Татарстанның дәүләт эшлеклеләре, алдынгы вуз ректорлары һәм төрле компания белгечләре Алабугага җыелды. «Түгәрәк өстәл»дә Казан федераль университеты ректоры Илшат Гафуров җитәкчелегендәге делегация дә катнашты.

Бүгенге көндә зонада 25 резидент эшли, яңа теркәлгәннәрен исәпләсәң, барлыгы – 29. Әлеге сан 2014 елда – 60 ка, ә 2020 елга 120 гә җитәчәк һәм эш урыннарының артуына китерәчәк. Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министры Айрат Шәфигуллин төбәктәге предприятиеләрне кадрлар белән тәэмин итү проблемасы яңа түгел икәнен һәм аны мәшгульлек үзәкләре, уку йортлары белән бергә чишәргә кирәклеген әйтте.

Уку йортлары вәкилләре арасында беренче булып КФУ ректоры Илшат Гафуров чыгыш ясады. Белгечләрнең белем дәрәҗәсе эш белән тәэмин итүчеләр таләпләренә туры килсен өчен, Казан университеты Америка, Европа илләре һәм Япониянең иң алдынгы уку йортлары белән берлектә лабораторияләр ача. Шуңа күрә вуз зонага кадрлар әзерләү яисә яңадан әзерләү белән ярдәм итә ала. Гомумән, Казан федераль университеты икътисад өлкәсендә үсеш алган яңа юнәлешләрне тормышка ашыра торган үзенчәлекле полигон булып тора. Ректор Илшат Гафуров КФУда әзерләнә торган белгечләр турында сөйләде, аларга бөтен дөнья буенча сорау зур икәнлеген ассызыклады.

Илшат Гафуров белгечләрнең чит илгә китү проблемасына да кагылды. Аның сүзләренчә, бу халыкара фондларның күп булуы белән аңлатыла. «Кызганычка каршы, бездә эш белән тәэмин итүчеләр бу өлкәдә артык активлык күрсәтми. Ә вузларны кирәк булмаган һөнәр ияләре әзерлисез дип тәнкыйтьлиләр. Үзләре белгечләргә карата булган профессиональ стандартларны формалаштыра алмыйлар. Шуңа күрә без эш бирүчеләр белән бергә-бергә эшләргә әзер», – диде ул һәм IT-парк белән хезмәттәшлек, анда студентларның II-III курстан ук практика үтә башлаулары турында сөйләде. Аның фикеренчә, IT-технологияләрне предприятиеләрдә дә үстерергә мөмкин. Университет ягыннан Н.И.Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институты, Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты, Мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системаларның югары мәктәбе ярдәмгә килә ала.

Шулай ук экология юнәлеше буенча да уртак проектларны тормышка ашырырга мөмкин. Экологик куркынычсызлык, чыгарылган продукциянең экологик характеристикасы кебек проблемалар Экология һәм география институты, биология һәм туфракны өйрәнү факультеты белән элемтәләрне ныгытырга мөмкинлек бирә.

Уку йортының тагын бер уңышлы килешүе турында мәгълүмат бирелде. КФУ каршында эшли торган технопарк фәнни эшләнмәләрне тормышка ашыра. Биредә кара алтын химиясе, медицина җиһазлары әзерләү юнәлешләре буенча эшлиләр.

Утырыштан соң делегация зонадагы иң эре производстволар белән таныште. Визит КФУ ның Алабуга институтына бару белән тәгәлләнде.

*«Бизнес-онлайн» интернет-газетасы мәгълүматлары файдаланылды.*

## • «Белем бирү һәм карьера – 2012»

# Ярминкә гөрли

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

Казан ярминкәсенә кичә яшьләр агылды, чөнки 11-13 апрель көннәрендә монда «Белем бирү һәм карьера» күргәзмәсе эшли башлады. Республиканың төрле районнарыннан һәм шулай ук Казан шәһәре мәктәпләреннән килгән укытучылар күргәзмәгә куелган материалларны кызыксынып карады, бүләк итеп әзерләнгән мәгълүматларны да бик рәхмәтле булып алдылар. Мондый бай эчтәлекле күргәзмәләрне район җирлекләрендә дә үткәреп булмасмы икән, дигән тәкъдимнәр дә булды.



Алия Галимуллина фотосы

● Халыкара багланышлар

# Технология һәм фән бердәмлеге

Динә МӨХТӘСИПОВА,
хәбәрче

9 апрель көнне Казан федераль университеты белән «Шлюмберже» компаниясе арасында уртак фәнни һәм укыту эшчәнлеге, студентларны практика үткәртү һәм эшкә урнаштыру мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итү һәм программалы продуктларны уку йортына кертү турындагы килешүләргә кул куелды.



Әмир Фазлыйәхмәтов фотосы

Әйтергә кирәк, әлеге компания кара алтын һәм газ сәнәгате буенча дөнья күләмендә лидерлардан санала. Кара алтын табу технологияләренең, проект һәм мәгълүмати чишелешләрне хәл итүнең заманча спектрлары кулланыла. Кунаклар арасында «Шлюмберже»ның Россиядәге һәм Урта Азиядәге хезмәткәрләр буенча директоры Артём Карапетов, компаниянең вице-президенты Денис Петраков, хезмәткәрләрне эшкә алу һәм университетлар белән эшләү бүлеге җитәкчесе Сергей Киреев, эшмәкәрлекне үстерү буенча менеджер Андрей Аверин, шулай ук Россиядә һәм Урта Азиядә университетлар белән эшләүче проектлар координаторы Вера Батутина, «Шлюмберже»ның университетлар белән эшләү буенча белгече Мария Сидорова бар иде. Компания вәкилләре Казан университеты тарихы музее, Штукенберг исемендәге геология музее, Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты эшчәнлеге белән танышты.

Хәтерләсәгез, КФУ делегациясе шушы көннәрдә Канадада булып кайтты. Әлеге визит турында Фәнни эшчәнлек буенча проректор Данис Нургалиев сөйләде. Алар Калгари, Альберта университетларында, Санкор Энерджи Корп төп офисында булды. Бүгенге көндә Канаданың алдынгы университетлары белән халыкара хезмәттәшлекнең яңа шартларын формалаштыру эше бара, «Шлюмберже» компаниясе белән ике як өчен дә файдалы булган элемтәләр барлыкка килә. «Республика җитәкчелеге Казан университетын авыр һәм битум кара алтын җитештерү өлкәсендә алдынгы уку йорты итеп билгеләде. Без әлеге аспектны визит барышында максатчан рәвештә өйрәндек», – диде ректор Илшат Гафуров.

Әлеге әһәмиятле документларга КФУ ректоры Илшат Гафуров һәм «Шлюмберже»ның Россиядәге һәм Урта Азиядәге хезмәткәрләр буенча директоры Артём Карапетов кул куйды. «Илебезнең тарихи университетлары белән килешү төзү – зур дәрәҗә. Технология һәм фән – безнең уртак тамырларыбыз. Кайбер проектларны КФУда тормышка ашыра алырбыз дип уйлыйм. Беренче адым булып технологияләр белән уртаклашу торса, киләчәктә хезмәттәшлекнең яңа дәрәҗәләренә чыгарбыз, ягъни уртак фәнни эшләр алып барырбыз», – диде Артём Карапетов.

● Галимнәребез

# Мөгаллимнәр мөгаллиме

Сиринә ТРОФИМОВА,
хәбәрче



Шушы көннәрдә КФУ ның Педагогика һәм психология институты каршында эшләп килүче Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге коллективында сөенечле вакыйга булды. Үзәк директоры – икътисад фәннәре докторы, профессор Рәис Фәлих улы ШӘЙХЕЛИСЛАМОВка «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Университет галимнәренең эшчәнлеге һәм тормыш юллары турында сөйләшүебезне дәвам итеп, укытучылар укытучысы булган үзенчәлекле шәхес, күренекле галим, оста җитәкче Рәис Шәйхелисламовка тукталдык.

Рәис Фәлих улы 1951 елда Мөслим районының Мөслим авылында туган. Эшчән, биш балалы гаиләдә яшьтән хезмәт тәрбиясе алып үсә ул. Мәктәптә укыганда, үзен актив укучы буларак күрсәтә. Яхшы укудан тыш, спорт ярышларында да катнаша, команда белән дә, үзе дә җиңүләргә еш ирешә. Мылтыктан ату һәм биеклеккә сикерү буенча район чемпионы да була.

«Рәис Фәлих улын мин V класстан бирле укыттым. Аның кайсы класс бүлмәсендә, кайсы партада һәм кем белән утырганын да хәтерлим. Ул бик тырыш, пөхтә, төгәл укучы булды. Барлык фәннәрне дә тигез яратты һәм нигезле итеп үзләштерде. Язучыларга багышлап үткәрелгән кичәләрдә дә Рәис укытучыларның зур терәге булды, чөнки ул бик матур итеп рус һәм татар җырларын башкара иде. Рәисләр гаиләсендә биш малай үсте. Әтиләре – гармунчы, җырчы. Шуңа күрә малайлары да җырга-моңга гашыйк булып үстеләр»,– дип искә төшерә Рәис Фәлиховичның рус теле һәм әдәбияты укытучысы Чәчкә Галиева.

1986 елда фән өлкәсендә көчен сынарга карар кылган Р.Шәйхелисламов, катлаулы хезмәт юлы үтеп, югары дәрәҗәләргә ирешә. Алабуга педагогия институтының Яр Чаллы филиалына, Яр Чаллы педагогия институты оешкач, анда эшли, мәгариф органнары белән бәйләнештә була, фән яңалыкларын мәктәпләргә, башка уку йортларына кертүдә актив катнаша. 1992 елда Рәис Фәлиховичны Чаллы шәһәренең халык мәгариф идарәсенә җитәкче итеп билгелиләр. 1997 елны Чаллыда Казан университетының беренче филиалы оеша һәм Р.Шәйхелисламов аның директоры итеп билгеләнә.

«Җитәкче урынында икътисад, финанс мәсьәләләрен белмичә, уңышлы эшләп булмый», – дип саный ул. 2002 елда икътисад фәннәре докторы дигән гыйльми исем алыр өчен, диссертация яклый. Ике елдан Р.Шәйхелисламов Мәгариф һәм фән министры итеп билгеләнә. 2007 елдан хәзерге көнгә кадәр ул мәгариф хезмәткәрләренең белемен камилләштерү өлкәсендә барлык тырышлыгын куеп эшли. Исеменә күрә – җисеме, дигәндәй, Рәис исеменең татарчасы «җитәкче» дигәнне аңлата. Менә шундый галимнәр эшли КФУда. Киләчәктә дә зур уңышларга ирешүегезне телибез!

● Бәйге

# Туган телдән башлыйк!

Зилә ФӘСХИЕВА,
хәбәрче

4-6 апрель көннәрендә Казанда «Полиглот – 2013» бөтенроссия конкурсының финалы үтте. Чараның төп максаты – 2013 елда Казанда үтәчәк Универсиадага волонтер-атташе һәм тәрҗемәчеләр туплау. Шушы һ.б. сораулар белән без филология фәннәре докторы, профессор, Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институтының роман-герман телләре кафедрасы мөдире, конкурсның жюри рәисе Венера Нәфыйк кызы ХИСАМОВАга мөрәҗәгать иттек.

**– Венера Нәфыйковна, әлеге чараның әһәмияте нинди?**

– КФУ, Универсиада дирекциясе һәм Студентлар лигасы тарафыннан уздырылган полиглотлар конкурсы ул, бердән, тел белгечләрен барлауны максат итеп куйса, икенчедән, сәләтле яшьләребезгә тагын да зуррак мөмкинлекләр ача. Бу чарада республикабыздан, Мәскәү, Ижау, Уфа, Пенза, Саранск, Екатеринбург, Пенза, Самара, Йошкар-Ола, Саратов, Волгоград һ.б. өлкәләрдән барлыгы 126 полиглот катнашты. Үзебезнең Казан федераль университетына 15 кешелек квота бирелде.

**– Студентларның белемнәрен ничек сынадыгыз?**

– Әйтергә кирәк, күбрәк дүртенче һәм бишенче курста укучылар катнашты. Аларга мәҗбүри рәвештә инглиз, француз, немец, испан, кытай һәм гарәп телләре арасыннан ике тел белү йөкләнгән иде. Биремнәре бик югары – Professional дәрәҗәсендә икәнен дә истә тотсак, студентларның күп хезмәт куйганы, зур көч түккәне күренеп тора. Аларның ишетеп аңлау, сөйләшү, язу, грамматика, теләсә-нинди темага әңгәмә оештыра алуларын күзәттек. Жюрида туган теле чит тел булган белгечләр дә бар иде. Чарага нәтиҗә ясалгач, мин зур канәгатьләнү хисе, матур фикерләр белән киттем. Хәзерге яшьләр шулкадәр тәрбияле, тырыш ки, аларга карап, үзең дә рухланып эшли башлыйсың. Димәк, безнең киләчәгебез бар икән, дип уйлыйсың. Гомуми исәпләүләрдән соң, без Саратов ягыннан килгән студентларга беренчелекне бирдек.

**– Катнашучыларга нинди шартлар тудырылган иде?**

– Студентлар чара дәвамында «Идел» яшьләр үзәгендә булды. Мондагы шартлар бик югары дәрәҗәдә иде, ашау-эчү, буш вакытларын планлаштыру, дискотекалар, уеннар – барысы да төгәл, дисциплиналы итеп оештырылган. Бу яктан КФУның медик-профилактик һәм психологик ярдәм күрсәтү үзәгендә эшләүче кызыбыз Регина Хәкимова бик зур осталык күрсәтте. Үз эшенең чын белгече икәнен күреп кайттык. Гомумән, конкурска ныклап әзерләнгәннәр, барлык оештыручыларга Афәрин!

**– Венера Нәфыйковна, Сез үзегез кайсы телләрне беләсез?**

– Татар һәм рус телләреннән кала, инглиз һәм төрек телләрен камил беләм дип уйлыйм. Шундый мәкаль дә бар бит: «Күпме күбрәк тел белсәң, син шулкадәр дәрәҗәдә Кеше исеменә лаек». Дөрестән дә, бүгенге цивилизацияле тормышта яшьләргә бигрәк тә тырышырга кирәк. Телләр өйрәнү мәсьәләсенә дә зур җаваплылык, тырышлык белән карасалар, алга таба күпкә җиңелрәк һәм мөмкинлекләре дә зуррак булачак!

**– Чит телләр буенча белгеч буларак, яңа гына икенче бер телне үзләштерә башлаучыларга нинди киңәшләр бирер идегез?**

– Бу сорау белән миңа бик еш мөрәҗәгать итәләр. Мәсәлән, инглиз телен өйрәнә башлар өчен, алдан сүзлек запасы булдырырга кирәк, сүзләрне хәтердә калдыру, һәрдаим баетып тору – тел өйрәнү процессында бик мөһим аспект. Аннары инде җөмлә калыпларына сала башлыйсың: җөмләнең иясе, хәбәре кайда урнаша һәм башкалары. Шуны әйтергә оныткanмын: чит телне өйрәнә башлаганчы, иң элек үзеңнең туган тел грамматикасын бик яхшы дәрәҗәдә белергә кирәк! Ә калганы тырышлыктан тора. Студентлар да тырышсыннар, ялкаулыкларын җиңә белеп, югарыга омтылсыннар иде. «Полиглот – 2013» кебек конкурсларда катнашыр өчен, бары үз-үзеңә ышаныч һәм максатчан булу кирәк!

**– Кызыклы әңгәмәгез өчен рәхмәт Сезгә!**



Җиңүнең 67 еллыгына

# Дәһшәтле еллар кайтавазы

Роза ХӘМИТОВА

Заманында безнең университетта белем алган Роза Хәмитова – сугыш елы баласы. Аның хатирәләрендә дәһшәтле сугыш нинди эз калдырган?! Юк, аның гына түгел, ә бөтен сугыш чоры балаларында... Көндәлек битләрендә – ачы хакыйкать.



***

Юкка балалар, зурлардан аермалы буларак, башкача, җиңел фикер йөртә, дип уйлыйлар. Сугышның өч елының кыйпылчыгын үз эченә алган әлеге көндәлектә ике яшь ярымлык кызның уйлары чагыла.

Караңгы Бикәй авылы. Сугыш. Ул бик еракта кебек, фашистлар янәшәдә түгел, пулялар сызгырмый, күктән ядрәләр яумый. Ләкин болар барысы да була ала. Шул «була ала» гыйбарәсе борчый. Борчылу беркайчан да бетмәячәк. Ул 65 яшьлекләр йөрәгендә бүген дә яши.

*Казан. Май. 2005 ел*

***

Уянам. Сагыш. Әни юк. Кырыемда сеңлем Алсу бар. Сәкедә ятабыз. Бу бераз ятрак. Хәзер без әни белән Бикәйдә яшибез. Әни мәктәптә. Ул анда балалар укыта.

Сикереп торам һәм ишеккә йөгерәм. Теге якта – зур мичле бүтән бүлмә. Анда да сәке бар. Ә сәкедә, шакмаклы кызыл эскәтер тирәли кешеләр утырышкан: зурлар да, балалар да бар. Уртада – олы савыт. Барысы да шуннан кашыклар белән тыгылып аш алалар да сак кына авызларына китерәләр. Бу «фатир» хуҗалары – Гәкифә апа, Ибни абый һәм аларның балалары.

*1942 ел. Май*

***

Без әни белән кабер янәшәсендә торабыз. Ибни абый казый. Алсуны күмәбез. Ул кызамыктан үлде.

*1942 ел. Җәй*

***

Ибни абыйлардан Аксинә әбиләр өенә күчәбез. Әни мине күтәргән. Ул озын гәүдәле. Тузанлы юл бик аста, еракта кебек тоела, куркыныч. Әбинең өе дә, өй алды да, бүлмәсе дә, миче дә бик зур. Мич башында – әбинең ятагы. Безнең караватмич авызына якын гына урнашкан.

*1942 ел. Җәй*

***

Әбинең ишегалды да, бакчасы да зур. Бәрәңге һәм бояр җиләге үсә. Аның вак кына кызыл җимешләре тәлгәш-тәлгәш салынып торалар. Әлеге вак җимешләрне өзеп алдым, бармакларым белән сыттым, фу, исе бигрәк тәмсез, ялап карадым – кабарлык түгел. Әби шул җимешләр белән самовар чистартам, ди.

Кич белән зур сыер кайта, мөгри-мөгри дә абзарга кереп китә. Әби аны сава, сөтен савытларга, кувшиннарга салып куя. Кулларыннан сөт исе килә.

Абзарда тавыклар кыталый. Алар миңа йомырка бирәләр.

Зур, авыр капкалардан йортның ишек төбенә таба басудан алып кайткан ак ташлардан сукмак сузыла. Аларда сикереп йөрүе күңелле. Бердәнбер курчагым кулымнан ничек шуып төште соң? Ул шундый тыгыз, җылы, ә башы фарфордан эшләнгән, күзләре зәңгәр. Башы чәлпәрәмә килде... Хәзер курчаксыз да калдым. Башсыз курчак булармы инде? Кычкырып-кычкырып елыйм, әле беркайчан да болай елаганым юк иде. Бетте! Курчагым да булмый инде хәзер. Сугыш бара бит. Ашарга юк, уенчыклар юк, кием юк, әти дә юк. Ул сугышта.

Өйгә кергән бер кеше миңа сорау бирә:

– Роза, ә синең әтиең кая?

– Сугышта...

– Ул анда нишли соң?

– Немецлар белән сугыша.

*1942 ел. Сентябрь*

***(Дәвамы киләсе саннарда).***

Әдәп-әхлак

# Әйткән сүз - аткан ук

Зилә ФӘСХИЕВА,
хәбәрче

«Кешеләр барыннан да бигрәк үзләренә кагылмаган әйберләр белән кызыксына», – дип язган Джордж Бернард Шоу.



Динебез буенча мөселманнар дуслык, тынычлыкта, бер-берсенә карата ихтирамлы булып яшәргә тиеш. Әмма кешеләр арасындагы дуслык, кардәшлек хисләрен бетереп, капма-каршылык яки дошманлык китереп чыгара торган нәрсәләрнең берсе – гайбәт сөйләү алгы планга чыга. Уйлап карасаң, кеше күп очракта ишеткәнен дә, ишетмәгәнен дә иптәшенә, танышына әйтеп калырга ашыга. «Тозлап-борычлап», каймагын да өстәп җибәрә. Шулай итеп, берберенә карата ышаныч кими һәм якын кешеләр дә читләшә башлый. Гайбәттән, сүз йөртүдән, кешеләрне рәнҗетә торган ямьсез һәм начар сүзләрдән һәрвакыт тартынырга кирәклеге онытылып китә...

Ислам динендә гайбәт сөйләү – зур гөнаһларның берседер, дигән караш бар. Мөселман булган, тәрбияле, әхлаклы кеше, башкаларның гаебен эзләп, ул турыда тегендә-монда сөйләп йөрмәс. Уйлап эшли белә торган, теленә хуҗа була алырдай кеше үзенең иптәшенең хатасын яки гаебен сер итеп сакларга тырышыр. Берәүнең кыек ягын сиңа килеп сөйләгән кеше башкалар янында синең хакта да ямьсез сүзләр сөйләмәс дип беребез дә әйтә алмый бит!

Шуңа күрә башкаларның гаепләрен тикшергәнче, беренче чиратта, үзебездә булган кимчелекләрне бетерергә, үзебезне яхшы кеше итеп тәрбияләргә тырышыйк. Сүзләребездә, эшләребездә, һәртөрле хәлләрдә дөрес эш итсәк кенә, без чын мәгънәсендә әхлаклы зат булырбыз!

Авиация һәм космонавтика көне

# Галәм киңлекләрендә

Алисә БИЛАЛОВА,
хәбәрче

12 апрельдә бөтен дөнья Авиация һәм космонавтика көнен билгеләп үтә. 1961 елда бу көнне Юрий Гагаринның «Восток» космик корабленда дөньяда беренче тапкыр галәм киңлекләренә чыкканын барыбыз да белә.

XXI гасырга аяк баскан көндә, без космик техниканың шаккатыргыч уңышларын күреп, ишетеп торабыз. Бүген Җир тирәли дистә меңләгән спутник әйләнә, космик аппаратлар айга, Венерага очыш ясады. Ә безнең университетыбыз халкының космонавтика белән кызыксынулары ни дәрәҗәдә? Галәм киңлекләре кызыксындырамы икән? Йолдызлар, ай, планеталар дөньясы бүгенге студентларны үзенә тартамы?



**Сөмбел Билалова,** сәнгать бүлеге студенты: «Минем өчен 12 апрель гадәти көн кебек. Ләкин аның нинди бай тарихлы булуын беләм. 1961 елның нәкъ 12 апрелендә Ю.Гагарин беренчеләрдән булып космоска оча. Бу дата мәктәптә уздырылган бәйгеләргә бәйле истә калган».



**Розалина Хәйруллина,** татар филологиясе бүлеге студенты: «Галәм җир шарыннан бик ерак булган кебек, космонавтика өлкәсе дә миннән шул ераклыкта. Бу өлкә мине кызыксындырмый. Башка планетада, миллионнарын әрәм итеп, җир алучыларны бөтенләй аңламыйм. Биеклектән куркам, шуңа космоска очу турында хыялланмыйм. Миңа җиремдә дә рәхәт!».



**Рәйсә Гарипова,** укыту-оештыру бүлеге хезмәткәре: «Космонавтика турында берни әйтә алмыйм, беркайчан да космонавт буласым килмәде, ә болай космос мине кызыксындыра, чиксез киңлек бит ул һәм аның күп серләре әле ачылмаган дип уйлыйм».



**Гөлчәчәк Гыйльметдинова,** юридик факультет студенты: «Космонавтика, әлбәттә, мине кызыксындыра... Бу бит кешенең бөеклеген дәлилли. Күпме еллар буе үз акылын камилләштереп, кешелек тәүге тапкыр космоска юл алган. Син күз алдыңа гына китереп кара: нинди катламнарны үтеп, космоска юл аласың, анда тибрәләсең... Боларның барысы да бит кеше кулы нәтиҗәсе. Ә бүгенге көндә бу өлкәдә булган белемнәрне тагын да камилләштерү бара: кешелек галәмгә очу юлын гына түгел, ә башка чит планеталарга әләгү мөмкинлекләрен дә эзли... Космоска омтылышым бар дип әйтү дөрес булырмы – белмим, чөнки ул организмның ныклыгын, чыдамлыгын, бик күп шөгыльләнүләр таләп итә. Ә менә анда ниләр бар һәм ничегрәк икән дип күз салырга теләр идем».



**Эльвира Закирова,** Филология һәм сәнгать институтының тәрбия эшләре бүлеге җитәкчесе: «Кызыксыну бар, миңа космос темасы бик якын. 12 апрель минем өчен балачактан гади кешенең космоска беренче тапкыр очу көне буларак таныш. Яшьлектә бу көн безнең буын өчен күбрәк мәгънәгә ия иде».



**Чулпан Гарифуллина,** немец теле бүлеге студенты: «Кызыксынам дип, йолдызларны телескоптан күзләп ятканым юк анысы. Шулай да Гагаринны герой дип саныйм. Ул беренче булырга, билгесезлеккә атларга батырчылык иткән. Үземдә космоска очу теләге юк, булмады да. Андагы ялгызлык, бушлык мине куркыта. Җирдә әле без туганнарыбыз, якыннарыбыз тирәсендә, яраткан университетыбыз бинасында – миңа шул да бик җиткән».



**Илгиз Мөхәммәтов,** Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты студенты: «Космос белән кызыксынмасам да, 12 апрель көне миңа балачактан ук таныш. Космоска очу турында хыялланыр яшьтә түгел инде хәзер. 10 ел элек бирәсе иде бу сорауны, бәлки, мин космонавт булырга хыялланам, дияр идем. Әйдә, космоска алып барам, дисәләр, очар идем, әлбәттә».



**Илшат Шәрәфетдинов,** чит телләр факультетының элеккеге студенты: «Әллә ни кызыксыну юк кебек... Шулай да космос, аның чиксез киңлекләре һәм серлелеге мине һәрчак үзенә тартып торды. Һәрвакыт анда да тормыш бармы икән, дип уйлана идем. 12 апрель – космоска очыш көне. Мин дә анда очу турында хыялланып яшим».

• Шәригать кушканча





Рамил Газизов фотолары

# Илаһи гүзәллек

Динара ӘХМӘТОВА,
хәбәрче

Гүзәллекне сүзләр белән генә аңлатып була микән? 6 апрель көнне К.Тинчурин исемендәге театрда узган мөселман модасы һәм милли киемнәр буенча яшь дизайнерларның Бөтенроссия конкурсында катнашучылар гүзәллеккә чикләр юк икәнен тагын бер кат исбатлады.

«Казан – мөселман мәдәниятенең башкаласы» дип исемләнгән конкурска барлыгы 40 тан артык гариза кабул ителгән. Финалга үткән 10 дизайнер бу көнне үз коллекциясен тәкъдим итте. Һәр чыгыш күз явын алырлык итеп эшләнгән. Костюмнарны күрсәтүче кызлар ярымшәрә модельләрдән аерылып тора. Тәкъдим ителгән костюмнарны гадәти тормышта да, бәйрәмнәргә дә киеп була. Төрле милли орнаментларыбызны саклап, шул ук вакытта заманча төсмерләр кушып тегелгән киемнәр хатын-кызның чибәрлеген тагын да ассызыклый. «Кара энҗе бөртеге», «Ясми», «Идел зәркәне» кебек коллекцияләр оригиналь, яшьләрчә булулары белән күзгә ташланды.

Хатын-кыз кайчан чибәрлекнең иң биек ноктасына менеп җитә? Минемчә, тормышында бер генә мәртәбә булырга тиешле никах көнендә. Биредә тәкъдим ителгән «Аккошлар», «Бәхет чәчәкләре» коллекциясен күрсәткән кызлар үзләре дә аккошлар кебек йөзеп кенә сәхнә түренә агылды.

Төп җиңүгә ия булган, Мәскәүдән финалга үткән берданбер «Бон А Жур» коллекциясендә француз стиле дә чагылыш тапты. Профессиональлек өчен гран-при алган «Сөембикә» коллекциясе язгы төсләр, натураль тукымалар, мехтан эшләнгән булуы белән игътибарны җәлеп итте.

Чарадан КФУ дизайнерлары да читтә калмады. Филология һәм сәнгать институтының «Tatarstyle» костюм студиясенең (җитәкче – доцент Рада Сәләхова) «Нурлы Казан» коллекциясен (авторы – Әнисә Рәхмәтуллова) мәртәбәле жюри «Иң яхшы татар костюмы» номинациясендә җиңүче дип тапты. Бу – киләчәккә тагын да зур стимул, яңа идеяләр чыганагы.

Мөселман киемнәренең шундый зур масштабка чыгуы – шатлыклы күренеш. Барлык хатын-кызлар да шундый киемнәрдән йөрсә, җәмгыятьтәге күп кенә проблемалар уңай якка хәл ителер иде дә бит. Иң мөһиме: алар заман артыннан куып, үз кыйммәтен югалтмасын иде.

**«UNIVER TV» күчтәнәче:**
*new.kpfu.ru/main_page?p_cid=5452&p_sub=8773*

• Идел киңлекләре

## «Апайсямен эктон»

Сиринә ТРОФИМОВА,
хәбәрче

*Әңгәмәдәшем – Балтач районы Сырья мәктәбе укытучысы, «Кенеш» дип аталган Балтач удмуртлары оешмасы рәисе Леонид Сапожников – үз халкының чын патриоты, башка милләтләргә зур хөрмәт белән караучы, татар телендә дә камил сөйләшүче шәхес.*

*«Без, 1980 еллар яшьләре, уенбиюләребезне күмәк күңел ачуларны 25-30 төрле көй белән үткәрә идек. Шул ук санга бер-ике татар көе дә керә: «Татар биюе» һәм «Беренче мәхәббәт» җырын удмуртча җырлый идек. Татар көйләрен, җырларын борынгы бабаларыбыз да үзләренә якын иткәннәр. Мәсәлән, «Апайсямен эктон» – «Апайларча» данлы биюебезнең кушымтасы татар сүзләренә әйләнгән:*

*Ай, бии Насьта,*
*Ска бия борыла.*
*Жива-дрива*
*Анасына борыла. (2 тапкыр)*
*Кызыбыз кала,*
*Җыламассың (яки сөенерсең),*
*Җырламассың.*

*1992 елда Балтач районындагы удмурт милли мәдәнияте җәмгыятенең әйдәп баручысы – «Азьлане» газетасының редакторы А.Кунаев газета аша укучыларга борынгы удмурт халык җырларын җыю турында әйткәч, удмурт халкы бу эшкә бик теләп алынды. Ун ел чамасы сузылган җыр җыю эшенә авылларыбыздан олы һәм урта яшьләрдәге абый-апалар чынлап тотынды. Үзләре белгән җыр сүзләрен иң кыйммәтле булган җаннары кебек, югалтулардан саклап калырга тырышып, «Азьлане» газетасына бер меңгә якын удмуртча җыр-такмак җибәрделәр.*

*«Апайларча бию» – ир-атлар уратып алган түгәрәк уртасында такмак һәм кул чабулар астында кыз биюе ул. Түгәрәк уртасына чиратлап чакырып биетеп, ир-атлар хатын-кызларга соклануын белдерә. Аларга булачак хатыннарын сайлауда әлеге бию әһәмиятле булып тора. Биюче кызның хәрәкәтләре орчык бөтерелүен хәтерләтә. Бөтерелгән вакытта биюче өч тапкыр юнәлешен алыштыра.*

*Борынгы заманнарда биючегә такмакны бары тик ир-атлар гына әйткән, калган кызлар түгәрәктән читтә үз чиратларын көтеп утырган. 1970 елларда әлеге традиция бозыла – барлык катнашучылар да такмак әйтә башлый. Бары хатын-кызлар гына башкарганга, бию «Апайларча бию» дип атала.*

• Спорт

# Сәламәт киләчәк өчен!

Динә МӨХТӘСИПОВА,
хәбәрче

7 апрель көнне Бөтен дөнья сәламәтлек көнен билгеләп үтте. Казан федераль университетында әлеге көн уңаеннан уку йорты хезмәткәрләре һәм студентлар өчен спорт чаралары узды.





Әмир Фазлыйәхмәтов фотолары

Сәламәтлек көнен 1948 елда Бөтендөнья сәламәтлекне саклау оешмасына нигез салынган көнне оештыра башлыйлар. Һәр елны әлеге көн өчен бер тема билгеләнә. Быел ул «Картаю һәм сәламәтлек» темасын яктыртып, «Яхшы сәламәтлек гомерне озайта» шигарен тормышка ашырды. Дөрестән дә, сәламәтлекне кайгырту өлкән яшьтә дә матур тормыш рәвеше алып барырга ярдәм итә. Безнең кем булуыбызга, кайда яшәвебезгә, җәмгыятьтә тоткан урыныбызга карамастан, барыбыз да вакыты җиткәч картаябыз шул.

Белгечләр фикеренчә, һәр көнне гимнастика ясаудан башларга кирәк. КФУда да сәламәтлек көне иртәнге күнегүләрне ясаудан башланып китте. Укуйортыбызның берничә спорт комплексында узган чараларда һәркем үзе теләгән спорт төре белән шөгыльләнә алды. «Мәскәү» спорткомплексына килүчеләр «Күңелле стартлар» ярышларында катнашты, тренажер залларында сәламәтлеген ныгытты. «Бустан»га аквааэробиканы яратучылар ашыкты. Ә «Уникс» спорткомплексында барлык спорт төре буенча да үз көчеңне сынарга була иде. Нәфис затлар – аэробика, ә егетләребез баскетбол буенча осталыкларын күрсәтте. Алай гына да түгел, гаилә медицинасы клиникасы табибы, психолог белән киңәшләшү, тренингларда катнашу мөмкинлеге тудырылды.

Шулай ук бу көнне һәр спорт төре буенча җиңү яулаучыларны да котладылар. Мине иң шаккатырганы шул: Филология һәм сәнгать институтының кул көрәше буенча җыелма командасы беренче урынга лаек булды. Нәрсәгә шакката, дисезме? Команданың күпчелеген кызлар тәшкил итә бит! Карап торышка модельләрдән бер дә ким булмаган нәфис затлар – кул көрәше буенча беренче! II курс студенты Гөлфия Шәвәлиева җиңәр өчен түгел, үзен сынап карар өчен ярышка килә. «Әлеге спорт төренә кереп китүем очраклы рәвештә генә килеп чыкты. Мәктәп елларында район күләмендә беренче урын алдым да шулай катнаша башладым. Бу юлы бер көн алдан ишеттем һәм катнашырга булдым. Мин бит авыл кызы, бөтен эштә әти-әниемә булышам. Әнием дә кул көрәшләрендә җиңү яулый, бәлки аңа охшаганмындыр», – ди Гөлфия.

Бу кызлардан үрнәк алырга кирәк. Үзләре укуда да өлгер, җәмәгать эшләрендә дә актив катнашалар, иҗатта да каләм чарлыйлар, җитмәсә, спортта да беренчеләр рәтендә. Татар кызлары шул. Җитмеш төрле һөнәр дә аз булган татар кызлары!

Башлаган сүземә кире кайтсак, сәламәтлекне 7 апрель көнне генә кайгыртырга ярамый. Аңа һәрвакыт зур игътибар бирелергә тиеш. Сәламәтлек – зур хәзинә. Байлыкка омтылган кебек, сәламәтлегебезне дә арттырсак иде.

**«UNIVER TV» күчтәнәче:**
*http://new.kpfu.ru/main_page?p_cid=5451&p_sub=8773*






DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.